
# Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре

# Җөмлә кисәкләренең шәҗәрә агачы.



**Баш килештә килеп, җөмләдә башка сүзләргә буйсынмаган кисәк … ИЯ**

кем? нәрсә? ни?

***Дус – акчадан кыйммәт.***

***татар халык мәкале***

**Җөмләнең ияse турында хәбәр итә һәм аның белән бәйләнеп килә торган икенче баш кисәге**

**ХӘБӘР ...**

нишли?, нишләр?, нишләгән?. нинди? күпме? һ.б.

***Эш кешене төзәтә, ялкаулык боза.***

*татар халык мәкале.*

1. Сизде эшне Шүрәле дә: кычкыра да бакыра.
Сызлана һәм ярдәменә шүрәлеләр чакыра ...
Тибрәнә дә йолкына, бичара гакълыннан шаша;
Шул арада яшь Җегет өйгә китәргә маташа.

(Габдулла Тукай)

2. Борын заман бер ир белән хатын торган.
Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган;
Асраганнар бер Кәҗә берлә Сарык,-
Болар булган берсеннән-берсе арык.

(Габдулла Тукай)

1. Балаларым! Басуыбыз эчендә бер хәзинә бар. Әмма кай җиренә күмелгән икәнен белә алмадым. (Дәрдемәнд)

2.Хәзер миңа элеккегә караганда да иртәрәк торырга туры килә. (А.Алиш)

3.Алдымда ак кар җәелгән ялтырап, ап-ак булып,
Энҗе-мәрҗәннәр чәчелгән өстенә вак-вак булып. (Ш. Бабич)


4. Ләкин бу биш-алты сәгать миңа күз ачып йому кадәрле дә тоелмады. (Г. Ибраһимов)

5. Агачлардан җанга ятыш әйбер ясар өчен, ничәмә ничә корал кулланалар. (Ф.Яруллин)

6.Ял итәргә, тамакны туйдырыга туктаган идек. (Г.Әпсәләмов)

7. Җиргә бассам арта егәрлегем,
Күккә баксам, иркен тын алам. (Э. Мөэминова)

8.Көн кичкә авышса да, үзенә күрә матурланып китте. (Х.Хәйруллин)



***Тәмле* сүзе түбәндәге җөмләләрдә җөмләнең кайсы кисәге булып килгән?**

*Тәмле* күп булмый.
Бала *тәмле* йокыга китте.
Мәче *тәмле* итеп иснәп куйды.
Әнием ясаган чәй бигрәк *тәмле*!

Җөмләдә ияртүче кисәктән соң килеп, аның мәгънәсенә өстәмә аныклык, төгәллек бирә торган иярчен кисәк ..аныклагыч

**Сусагандыр алар бу яңгырга –**
**Тал-тирәкләр шундый күперде!**
**Офыкларны бергә тоташтырды**
**Төсле дуга – салават күпере.**

***Җөмләне исегездә калдырып, хәтердән дәфтәрләрегезгә языгыз. Җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерегез.***

Сәлимнең сәләмә сыеры, сәнәккә сөртенеп, сыйрагын сындырган.

Тел шомарткыч

Сыйрагын - аягын

**Өй эше:**

***“Сабантуй”, “Татарстан яшьләре” газеталарыннан яки берәр әдәби әсәрдән 4 җөмлә язып алырга.***

1. ***Иясен һәм хәбәрен табарга;***
2. ***Баш һәм иярчен кисәкләрне табарга;***
3. ***Җөмлә кисәкләре ягыннан тикшереп, нинди сүз төркемнәре белән белдерүләрен өсләренә язарга.***